**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе төзү турында» үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе төзү турында» 2018 елның 3 маендагы ПУ-346 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2019 елның 24 гыйнварындагы ПУ-21 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе турында нигезләмәнең 4 пунктының «а» пунктчасында һәм 5 пунктының «а» пунктчасында «бирү» сүзен «тапшыру» сүзенә алмаштырырга;

б) күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген лицензияләү буенча Татарстан Республикасы лицензия комиссиясе (алга таба – Комиссия) составында:

Комиссия составыннан Р.М. Каюмованы, Л.С. Мортазинаны чыгарырга;

Комиссия составына кертергә:

Гаврилова Юлия Викторовнаны – Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлеген тәэмин итү бүлеге баш киңәшчесен;

Гобәев Марат Хөснулла улын – «Татарстан Республикасының күпфатирлы йортлар идарәчеләре оешмалары берлеге» ассоциациясенең үзкөйләнешле оешмасы Советы рәисен;

Комиссия әгъзалары вазыйфалары атамаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Р.К. Гаязовның – «Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе башлыгы урынбасары – Идарәнең коррупциягә каршы мониторинг бүлеге мөдире»;

К.Г. Садриевның – «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты рәисе урынбасары»;

Р.Р. Хәкимовның – «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының Торак хуҗалыгы идарәсе

торак фонды объектларын эксплуатацияләү һәм территорияләрне төзекләндерү бүлеге башлыгы».

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2021 ел, 01 февраль
№ ПУ-71